Проект

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы

КАРАР

«___» ___________ 2023 ел № ____

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегенең 2022 елгы
бюджеты үтәлеше турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2022 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләре нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.6 статьясына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 81, 82 статьяларына туры китереп,

Шәһәр Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2022 елгы бюджеты (алга таба – шәһәр бюджеты) үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 14 774 295 882,07 сум күләмендә, чыгымнар буенча 15 345 776 376,48 сум күләмендә, шәһәр бюджетын финанслау чыганаклары белән 571 480 494,41 сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1) бюджет керемнәре классификациясе кодлары буенча шәһәр бюджеты керемнәрен, 1 нче кушымтада каралганча;

2) бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча шәһәр бюджеты чыгымнарын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча шәһәр бюджеты чыгымнарын, 3 нче кушымтада каралганча;

4) бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын, 4 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Яр Чаллы шәһәре
Хакиме Н.Г. Мәһдиев